# Малайларга, кызларга@.RU

## *Февраль аена истәлекле даталар*

3 – Балет артисткасы, профессор Нинель Юлтыеваның тууына 90 ел (1926–2014).
Рәссам-график Тавил Хаҗиәхмәтовның тууына 80 ел (1936–2007).
6 – Фольклорчы галим, җәмәгать эшлеклесе Рәшит Ягъфәровның тууына 70 ел (1946–2008).
7 – Шагыйрә Илсөяр Иксановага 50 яшь.
8 – Актриса, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисткасы Шәхсәнәм Әсфәндиярованың тууына 90 ел (1926–1996).
10 – Язучы, тәрҗемәче Солтан Шәмсигә 70 яшь.
13 – Җырчы, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Вафирә Гыйззәтуллинаның тууына 70 ел (1946–2001).
15 – Россиядә интернационалист сугышчыларны искә алу көне.
Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 110 ел (1906–1944).
16 – 40 ел элек «КамАЗ» маркалы беренче автомобиль завод конвейерыннан төште.
19 – Композитор, Татарстанның халык артисты Александр Ключаревның тууына 110 ел (1906–1972).
21 – Халыкара туган тел көне.
Оренбургта татар телендә «Вакыт» газетасы чыга башлауга 110 ел (1906).
23 – Ватанны саклаучылар көне.
Н.И.Лобачевскийның неевклид геометриясен ачуына (аңа нигез салуына) 190 ел.
25 – Педагог, журналист, 1960–1977 елларда «Совет мәктәбе» (хәзерге «Мәгариф») журналының баш мөхәррире Фатих Ибраһимовның тууына 100 ел (1916–1999).
28 – Шагыйрә Шәмсия Җиһангировага 65 яшь.

# *Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты герой-шагыйрь Муса Җәлилнең туууына 110 ел (1906–1944).*



**Муса Җәлил** — политрук

Муса Җәлил Ырынбур өлкәсе Мостафа авылында туа.
Муса Ырынбурда «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. Җәйне туган авылында үткәрә. Муса 10-11 яшьләрендә шигырьләр язып карый. Ләкин алар югала. Матбугатта иң беренче булып унөч яшендә язылган «Бәхет» шигыре (1919) басыла. 1922 нче елда ул Казанга килә һәм 1923-1925 елларда Казан педагогия институтының рабфагында укый. 1925 нче елда Җәлилнең «Барабыз» исемле беренче китабы чыга. «Иптәшкә» (1929) дигән шигырь җыентыгы аның шагыйрь булып җитлегеп килүен тагын бер тапкыр раслый. Ул 1931 нче елда Мәскәү университетының әдәбият бүлеген тәмамлый. 1939 нчы елда Җәлилне Татарстан Язучылар берлегенең җитәкчесе итеп сайлыйлар. Сугышка кадәрге елларда шагыйрь бик күп шигырьләр, җырлар, «Хат ташучы» поэмасын, «Алтынчәч», «Илдар» исемле опера либреттоларын яза.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, ул үзен фронтка җибәрүләрен сорый. Аның үтенече канәгатьләндерелә. 1941 елның ноябрь-декабрь айларында Минзәләдә хәрби-сәяси җитәкчеләр (*политруклар*) әзерләүче кыска сроклы курсларны тәмамлап, «өлкән политрук» дәрәҗәсе ала. Ленинград фронтында фронт газетасында эшли башлый. 1942 нче елның җәендә Волхов фронтында, дошман чолганышында калып, авыр яраланган хәлдә, фашистлар кулына әсирлеккә эләгә. Әнә шулай аның лагерь тормышы башлана. Шагыйрь әсирлектә дә көрәшне туктатмый. Яшерен оешмага керә, аның җитәкчеләреннән берсе була, бик күп әсирләр белән лагерьдан качу һәм партизаннарга барып кушылу ниятен тормышка ашырырга уйлый. Бер хыянәтче аларның серләрен фашистларга хәбәр итә. Шуннан соң Җәлилне һәм аның иптәшләрен Берлиндагы Моабит төрмәсенә ябалар. Шагыйрь анда да туган иленә тугрылыклы булып кала. Искиткеч рухи ныклык күрсәтә. Үлем җәзасы көтеп торганда да, туган илгә, халыкка тирән мәхәббәт белән сугарылган, фашистларга көчле нәфрәтен белдергән шигырьләр язып, аларны үзе ясаган кечкенә дәфтәрләргә теркәп бара.

Җәлилнең әсирлектә язган шигырьләре бөтен дөньяга билгеле. Татарстанга аның ике дәфтәре кайтты. Аларны бөтен дөньяда«Моабит дәфтәрләре» дигән исем белән беләләр. Дәфтәрләр татар гарәп имләсендә һәм "Яңалиф" татар латин әлифбасында язылган. Беренче дәфтәренә Муса Җәлилнең алтмыш шигыре теркәлгән һәм дәфтәрнең соңгы битенә васыять язылган: *«Моны язды татарның билгеле шагыйре М.* Җәлил. 1942 елны сугышка килде һәм әсир төште. Әсирлектә күп газаплар чигеп, сәяси яшерен оешмага катнашуда гаепләнеп кулга алынды, төрмәгә ябылды. Бәлкем, аны үлем җәзасына хөкем итәрләр»*.*

Сугыштан соң совет шагыйре һәм язучысы Константин Симонов ярдәмендә Муса Җәлилнең шигырьләре бастырыла башлый, тәрҗемә ителә, шагыйрьнең батырлыгы бөтен дәүләткә билгеле була

**Муса һәйкәленә бер таш (“Муса” романына пролог)**
Таш кисүнең авыр икәненә
Карасыңмы,  яныпжилкенсәң?
Мин шат ,
Әгәр дуслар һәйкәленә
Җилкәм белән бер таш китерсәм.

*Шәйхи Маннур)*

**Җәлил кояшы.**
Кузгалалар эшафотка таба.
Бу гомернең соңгы “әкбәре”.
Сукты сәгать!Һәммәсенең бүген
Легендага күчкән мәлләре.
Палач каршы ала.Элеккечә
Тишек капчык түгел башында.
Юк ,башкарып булмый кара эшне
Беркайчан да кояш астында,-
Караңгыга ,төрмә төбенәрәк
Ымлый һаман.Көннең яктысы
Бәбкәләрен кисә.Тоткарланса
Исен җуяр адәм актыгы.
“Кеше башы шкияттәге кебек,
Кискән саен кабат үсә лә...”-
Фәлсәфәсе әзер, кереп түнгәч
Фәлән кадәр марка кесәгә.
Кояш кына менә ярсыта бик...
Дивар ышыгына сыенып,
Ул аны да өзеп алыр иде!
Тик кояшның юк шул муены...
Җәлил башын яшергән күк кичә,
Яшерер иде төннәр төбенә.
Хыялы буш ләкин.
Палачларның
Кулы җитми шагыйрь күгенә.

*Ркаил Зәйдулла,Җәлил премиясе лауреаты)*

“Сез күрәсез мине,
Мин сезне-юк!
Син
Фучик Җәлилләрне
Тар өнлекле камерага
Япкач,
Шулай диден,палач.Тик ялгыштың,
Синнән битәр.Кешелекне,

Йолдызларны
Чулпаннарын күрде алар.
Кисәкләп булса да
Кояшны күрделәр,
Ә нурларын күңелгә ялгап,
Җыр яздылар.
Үлмәс җыр!

*Равил Фәйзуллин,Җәлил премиясе лауреаты)*

**Үлемгә хөкем ителгәннәр төше**
Мин хөкем ителдем йөз яшькә
Кадәре картаймый яшәргә.
Мин кайттым,кадерлем,кил,кочыйм,
Карама чал төшкән чәчләргә.
Дөньяда коллар юк ,төрмә юк,
Онытылган золымнар,газаплар
Мин кайттым ,кадерлем,кил,кочыйм
Кулларым богаудан азатлар.
Төрмәнең нигезен актарып,
Ал гөлләр чәчегез,сеңелләр.
Мин кайттым,кадерлем,кил,кочыйм,
Кулларым богаулы түгелләр.
Карт дөнья иркенләп тын ала,
Толымың муеныма урала.
Мин кайттым,кадерлем,кил,кочыйм,
Елама,керфегең чылана...

*Илдар Юзеев, Җәлил премиясе лауреаты)*

**Без кайтырга тиеш!**
Туган илгә без кайтырга тиеш!-
Камил аңым,камил иманым да.
Кайтмый калсак,безнең татар халкы
Ни дип җавап бирер ил алдында?

Ак пакъ калсын,дисәк халык йөзе,
Кызармасын ,дисәк ватандашлар-
Безнең өчен,безнеңязмышөчен
Югалмаска тиеш безнең башлар.

Бездән башка да күп югалгандыр
Тарих тарафыннан кагылганнар-
Халкыбызның күпме газизләре
Хәтерләрдән йолкып алынганнар.

Үлем түгел үлемсезлек алда!

Күп калмады инде таңга кадәр –
Йә, хушыгыз, дуслар, көрәштәшләр,
Туган илдә очрашканга кадәр!

*Роберт Миңнуллин, Җәлил премиясе лауреаты.)*

**Җәлилләр ялкыны.**
Һәрвакыт уяумы, әзерме? –
Чакыра варислар быргысы.
Безгә бит бу чорны төзисе,
Заманның җырларын җырлыйсы.

Без уяу, без әзер,
Йөрәкләр һәрвакыт ялкынлы
Җәлилләр, Алишлар ялкыны
Мәңгелек ут булып балкыды.

Бәхеткә юл ярып барганда
Юлдаш ит һәрвакыт халкыңны!
Яшь калсын йөрәкләр мәңгегә,
Сүнмәсен Җәлилләр ялкыны!

*Разил Вәлиев, Җәлил премиясе лауреаты.)*

Муса Җәлил – татар халкының соклангыч улы, аның җырчысы һәм герое – бөтен халыкның сөекле шагыйренә, аның данына һәм горурлыгына әверелде.

**Марк Лисянский.**

Муса Җәлил!
Бу ике сүздә поэзия һәм батырлык гәүдәләнә.
Исән чагымда, йөрәгем типкән чакта, мин аларны кабатлап туймаячакмын.

**Степан Щипачев**

Минем өчен Муса Җәлил сынаулар һәм үлем каршында гражданлык һәм язучылык батырлыгы күрсәткән кешеләрнең бер үрнәге булды һәм булып кала.

Ул зур шагыйрь генә түгел, бәлки көчле рухлы батыр да, безнең аңа карата рәхмәт хисе йөргән күңелебезгә нәкъ шулай булып урнашкан зур кеше дә.

**Константин Симонов**

Кешелек хыялы кешеләргә ут биргән өчен таш кыяга кадакланган Прометей образын тудырган. Муса Җәлил үзенең батырлыгы белән Прометейдан югарырак күтәрелде дияр идем мин. Ул күңеленең сүнмәс утларын таратуны Моабитның таш стенасына кадакланган хәлдә дә дәвам иттерде.

**Кирәй Мәргән.**

Шагыйрь җиңүгә нык ышанды, һәм ул җиңү килде. Ватанның тантана итүе хакына иң кадерле нәрсәсе – тормышларын биргән күп санлы

геройлар арасында Муса Җәлил исеме һәрвакыт сүнмәс йолдыз булып балкыр.

**Петрусь Бровка.**

Легендалар белән бизәлгән, яктылыгын һичкайчан җуймаячак дан белән бүләкләнгән герой хәзер дә үзенең рухланып язылган шигъри юллары белән, туган Татарстанына эндәшкән кебек, Неман крае халкына, безнең бөек Ватаныбызга, ирек сөюче кешеләргә, Поэзиянең һәм Азатлыкның бөтен дөньядагы чын дусларына мөрәҗәгать итә.

**Эдвардас Межелайтис.**

Мин Җәлилне укыганда һәм аның хакында уйлаганда, аның бөтен гомере батырлык булып күз алдыма килеп баса. Аның белән замандашларыбыз горурлана һәм килен буын кешеләре дә аңа охшарга тырышырлар.

**М.Турсун – заде.**

Батырларның үлеме кояш батышына тиң...

**К.Маркс.**

Батырлык – игелеклелек; шуның аркасында кешеләр куркыныч хәлләрдә, законга таянып һәм аңа буйсынып, гүзәл эшләр башкаралар.

**Аристотель.**

Дөнья һәм дөнья әдәбияты – исемнәре иҗатларының мәңгелек данына әйләнгән күп кенә шагыйрьләрне белә. Ләкин шагыйрь һәм герой Муса Җәлил кебек, әсәрләре белән генә түгел, бәлки үлеме белән дә исемен мәңгеләштергән шагыйрьләр бик аз. Менә алар: бөек Байрон, Венгриянең данлыклы халык шагыйре Петефи, герой Юлиус Фучик һәм, ниһаять, Муса Җәлил.

**Сәмәд Вургун.**

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ Моабит шигырьләрендә без аның ялкынлы йөрәге тибешен ишетәбез, безгә шагыйрьнең тирән хисләре һәм уйлары, аның яшерен өметләре һәм омтылышлары ачыла.

**Леон Небенцаль.**

Без шуңа горурбыз: аның ялкынлы шигырьләре үзен үтерүчеләргә һәм дөньяны яңадан канга батырырга теләүчеләргә гаепләү акты булып, озак еллар буена яңгырап торачак.

**Мостай Кәрим – башкорт шагыйре.**

Аның “Моабит дәфтәре” – кешенең рухи батырлыгына һәйкәл, бу шигырьләр киләчәк буыннарны дулкынландырыр һәм аларда да аңа охшарга тырышу хисе тудырыр.

**Николай Тихонов – рус шагыйре.**

Палач балтасы астында шундый зирәк, Ватанга чиксез мәхәббәт, ә фашистларга карата җимергеч нәфрәт тулы ялкынлы юллар язу өчен тимер, сыгылмас ихтиярлы, якты акыллы, зур һәм кайнар йөрәкле кеше булырга кирзк.

**Петрусь Бровка.**

Гражданин һәм шагыйрь Муса Җәлил батырлыгында тугандаш татар халкының рухи матурлыгы, көчле зур җаны, бетмәс – төкәнмәс каршы торучанлык куәте чагылды.

**Рәсүл РЗА.**

“Мин үлемнән курыкмыйм. Бу буш сүз түгел. Без үлемгә җирәнеп карыйбыз дип әйтәбез икән, бу чыннан да шулай бит. Куркыныч хәлләргә очраган чакларда, мин үлем турында котым очып уйлап утыруымны белмим. Бөек патриотизм хисе, үзеңнең җәмәгать функцияңне тулысынча аңлау кешене шәхси курку хисләреннән өстен күтәрә. Үлем турында башка берәр уй килеп төшә икән, болай фикер йөртәсең: үлемнән соң да яшәү бар бит әле; бу – поплар, муллалар вәгъдә итә торган “теге дөнья” тормышы түгел, әлбәттә. “Теге дөнья”ның юклыгын без беләбез. Ә менә үлгәннән соң халык күңелендә, халык аңында яши торган тормыш бар. Әгәр дә мин исән чакта нинди дә булса әһәмиятле, үлми торган эш эшләп калдыра алсам, моның белән мин икенче кабат яшәргә - үлгәннән соң да яшәргә хокук алам. Чөнки минем турында сөйләячәкләр, язачаклар, ихтимал, рәсемнәрендә дә басып чыгарырлар. Әгәр мин шуңа ирешә алам икән, ни дип үлемнән куркырга? ДӨНЬЯДА ШУНДЫЙ ИТЕП ЯШӘРГӘ КИРӘК, ҮЛГӘННӘН СОҢ ДА ҮЛМӘСЛЕК БУЛСЫН – ЯШӘҮНЕҢ БӨТЕН МАКСАТЫ ШУНДА ТҮГЕЛМЕНИ?”

**Муса Җәлил.**

## *Блиц – турнир.*

1. Җәлилнең туган авылы. (Мостафа)
2. Җәлилнең әтисенең исеме.(Мостафа Җәлилов)
3. Җәлилнең әнисенең исеме (Рәхимә Җәлилова)
4. Җәлил ничәнче елда туа? (1906)
5. Мостафа авылы нинди елга буена урнашкан? (Нит)
6. Муса мәктәпкә ничә яшендә укырга керә? (алты)
7. Мәктәптә укыганда Мусага нинди кушамат тагалар?(“Кәтүк” )
8. Муса укыган мәдрәсә (Хөсәения)
9. Шагыйрьнең абыйсының исеме (Ибраһим), сеңелләренең исеме (Зәйнәп,Хәдичә)
10. Җәлилнең тормыш иптәше (Әминә)
11. Мусаның беренче басылып чыккан шигыре (Бәхет)
12. Мостафа авылында Муса Җәлил җитәкләгән балалар оешмасының исеме *(“Кызыл йолдыз”, ә соңыннан “Кызыл чәчәк”дип атала)*

## *«Кызыма»*

(М.Җәлил сүз. Ф. Шәймәрданова муз.)

Шаян кызым син минем,
Таң йолдызым син минем,
Йөрәгемдә балкыган
Шатлык җырым син минем.

Синең гомрең җыр булып
Янар бәхет илендә,
Йолдыз булып янарсың
Син туган ил күгендә.

Таңнан торып, бакчада
Син уйнадың көн озын.
Аргансыңдыр, кил, кызым,
Йокла инде, йолдызым!
Әлли - бәлли, бәлли –бәү!
Әлли –бәлли, бәлли –бәү!

## *"Тик булса иде ирек"*

Карлыгач булса идем,
Канат кагынса идем,
Җидегән йолдыз батканда,
Чулпан йолдыз калыкканда,
        Туган илем, якты өем,
        Очып сиңа кайтыр идем,
        Сызылып таңнар атканда.
        Булсам җитез аргамак,
Көмеш ялымны тарап,
Таң җилләре искәндә,
Үләнгә чык төшкәндә,
Чулпан кызым, таң йолдызым,
        Чабып сиңа кайтыр идем,
        Гөлләр хуш ис сипкәндә.
        Юк, барысыннан да элек
        Тик булса иде ирек.
Кылычым булса канымда,
Сине саклап, туган җирем,
Мин ирләрчә үлер идем
Данлы сугыш кырында.